**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 21.06.2021** **№ 538**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 апрелендәге 276 номерлы «Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 13 декабрендәге 326 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Түбәндә китерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү турында килешүне (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 елның
21.06.2021 № 538 карарына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, җирлекләрне төзекләндерү кысаларында даими файдалану хокукында, арендалау яисә түләүсез файдалану хокукында хуҗалык итүче субъектларга бирелгән кишәрлекләрдән тыш, үсеп чыккан Сосновский балтырганын юк итү чараларын үтәүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели, (алга таба - субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) Сосновский балтырганын юк итү чаралары).

Әлеге Тәртипне куллану максатларында Сосновский балтырганын юк итү чаралары дигәндә механик (кулдан һәм (яисә) механик чаптыру, бульдозер белән кистерү, фреза эшкәртүе һәм башка чаралар) һәм (яисә) Сосновский балтырганы белән чүпләнгән территорияләрне химик (гербицидлар белән) эшкәртү чаралары комплексы аңлашыла.

2. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына бирелә торган акчалар исәбеннән, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, әлеге тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты турында карары белән расланган максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыга кадәр җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм лимитлары исәбеннән бирелә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре белгечләре катнашында Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнарны билгеләү өчен комиссия төзи.

4. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү өчен сайлап алу критерие булып Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнар булу тора.

5.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре

бюджетларына субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының уртак финанслanулары максатларында субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирелә торган чаралар исемлеген һәм чараларны үткәрү тәртибен раслый торган муниципаль хокукый акты булу;

б) җирлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет язмасында), Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүне планлаштыру күләмен дә кертеп) аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә, уртак финанслануы максатларында муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирелә торган бюджет ассигнованиеләре булу;

в) уртак финанслануы максатларында субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча җирлек йөкләмәләрен үтәүне күздә тоткан килешү төзү һәм күрсәтелгән килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

6. Субсидия (башка бюджетара трансферт) алу өчен җирлек субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүгә заявка җибәрә.

7. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары счетларына күчерелә, алар заявка алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларга күчерелә.

8. Субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалану нәтиҗәсе булып муниципаль берәмлек территориясендә Сосновский балтырганын юк итү чаралары үткәрелгән җир кишәрлекләре мәйданы (гектарларда) санала.

9. Субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) куллану нәтиҗәсенең агымдагы финанс елында фактта ирешелгән күрсәткечләрен, килешүдә каралган субсидиядән файдалану нәтиҗәсенең күрсәткечләре белән чагыштыру юлы белән башкарыла.

10. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) куллану һәм Килешүдә каралган форма һәм сроклар буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап бирәләр.

11. Әлеге Тәртип нигезендә алынган агымдагы финанс елының 31 декабре торышына файдаланылмаган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.

12. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартларын үтәмәгән өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

13. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

14. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны контрольдә тоту законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский балтырганынын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү тәртибенә

20___ елның "___"______ Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский борщевигын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүгә
ЗАЯВКА

Сумнарда

| АЛУЧЫ | КФСР | КЦСР | КВР | Сумма | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Сумма сүзләр белән ________________________________________________
________________________________________________________________

Җитәкче _________________ (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер _________________ (Ф.И.А.)

му

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның
21.06.2021 № 538 карарына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына Сосновский борщевигын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү турында**
**КИЛЕШҮ**

«__» ________________, 20__ ел                                    № __________

Алга таба уртак телгә алынганда «Яклар» дип аталучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 19 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә эш итүче алга таба «Район башкарма комитеты» дип аталачак Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, Башкарма комитет җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин йөзендә бер яктан, һәм Устав нигезендә эш итүче, алга таба «җирлекнең башкарма комитеты» дип аталачак Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы _________________ җирлеге башкарма комитеты, җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе ______________________ йөзендә икенче яктан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан максатчан билгеләнешле Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының 2019 елның 13 ноябрендәге 326 номерлы карары белән расланган Башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре (алга таба - Башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре), Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 13 ноябрендәге 327 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы бюджетыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре нигезендә, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

## I. Килешүнең предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан 20_____ елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы ____________ җирлеге бюджетына муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, хуҗалык итүче субъектларга даими файдалану хокукында авыл

территорияләрен төзекләндерү чараларын үткәрүгә бирелгән кишәрлекләрдән тыш, үсеп чыккан Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар (алга таба - субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү тора.

## II. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының _________ елның _______ №__ __________ һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының __________елның «____»________ №______ боерыгы нигезендә финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак район Башкарма комитетына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2.2. Район Башкарма комитеты субсидияләрне (башка бюджетара трансфертлар) «Биектау муниципаль районы ___________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан 20__ елда Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә _______ (____________________) сум ___ тиен күләмдә бирә

шул исәптән:

- ________(_________________________________) сум _____ тиен күләмдә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан;
- ________(_________________________________) сум _____ тиен күләмдә Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары хисабыннан.

## III. Субсидия (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү һәм аларны тоту шартлары булып субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү турында килешү төзү тора.

3.2. Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) алу өчен җирлек башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) районның башкарма комитеты билгеләгән срокларда район башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

аның аерылгысыз өлеше булып торган әлеге Килешүгә 1 нче кушымта нигезендә Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүгә заявка;

башка документлар.

3.3. Акчаларны күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекчәсендә җирле бюджетлар түләлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган җирлекнең башкарма комитетына ачылган счетка гамәлгә ашырыла.

## IV. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Район Башкарма комитеты бурычлы:

4.1.1. Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары үтәлгәндә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән тәртиптә районның башкарма комитетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак җиткерелгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүне тәэмин итәргә.

4.1.2. Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешүдә каралган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) һәм башка йөкләмәләр бирү шартлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга.

4.1.3. Финанс тәэминаты чыганагы максатчан билгеләнеше булган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) исәбеннән башкарылган чыгымнарны раслый торган документларны Татарстан Республикасы бюджетыннан тикшерүне гамәлгә ашырырга.

4.1.4. Субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү йөкләмәләрен исәпкә алып, җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган хисаплылык күрсәткечләре нигезендә субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) файдалануны бәяләүне гамәлгә ашырырга.

4.1.5. Россия Федерациясе бюджет законнарында, башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.2. Район Башкарма комитеты хокуклы:

4.2.1. Җирлек башкарма комитетыннан субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары һәм килешүдә каралган башка йөкләмәләр үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе күрсәткечләрен һәм җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартларын үтәүгә бәйле беренчел документацияне соратып алырга.

4.2.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында, Субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.3. Җирлек башкарма комитеты бурычлы:

4.3.1. Әлеге Килешүнең 3.1 пунктында билгеләнгән субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары үтәлешен тәэмин итәргә.

4.3.2. Башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренең 11, 13 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына акчалар кайтару буенча район башкарма комитеты таләпләренең үтәлешен тәэмин итәргә.

4.3.3. Әлеге максатларга акчалар бирү турында Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре билгеләренә ирешүне тәэмин итәргә.

4.3.4. Финанс тәэмин итү чыганагы булып максатчан билгеләнешкә ия Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (башка бюджетара

трансфертлар) булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан килгән субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалану турында район Башкарма комитетына, әлеге Килешүгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча, квартал саен хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча хисап тапшыру мөмкинлеген тәэмин итәргә.

4.3.5. Сорату алган очракта, җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү шартлары һәм килешүдә каралган башка йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту өчен кирәкле документлар һәм материаллар, шул исәптән субсидияләрдән (башка бюджетара трансфертлардан) файдалану белән бәйле бухгалтерлык исәбе белешмәләре һәм беренчел документацияне бирүне тәэмин итәргә.

4.3.6. Хисап чорыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең (башка бюджетара трансфертларның) калган өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда кире кайтарырга.

4.3.7. Россия Федерациясе бюджет законнарында, Башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.4. Җирлек башкарма комитеты хокуклы:

4.4.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә район Башкарма комитетына аңлатмалар сорап мөрәҗәгать итәргә.

4.4.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында, Башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

5.2. Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан бүлеп бирелгән трансфертлардан максатчан файдаланылмаган очракта, җирлекнең башкарма комитеты билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән тәртиптә файдаланылмаган акчаларны Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы бюджетына кайтара һәм тиешле эшләрне башкаруны җирлек бюджеты акчалары исәбеннән тәэмин итә.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр, мөмкин булганча, беркетмәләрне яисә башка документларны рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгән очракта, Яклар арасында бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокукы булган затлар аңа имза салган датадан үз көченә керә, әмма әлеге Килешүне предметы буенча җирле бюджетка бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән дә иртәрәк түгел, һәм Якларның әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәвенә кадәр гамәлдә була.

Әлеге Килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта, әлеге Килешү буенча якларның йөкләмәләре туктатыла.

6.3. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр бер яисә ике Якның да инициативасы белән язма рәвештә кертелә һәм әлеге Килешүгә карата аның аерылгысыз өлешенә әверелүче өстәмә килешүләр рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.4. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

Урнашкан урыны:
Банк реквизитлары:
БИК һәм Россия Банкы учреждениесенең исеме
Исәп-хисап счеты
Шәхси счет
ИНН/КПП
ОГРН
ОКТМО

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы _____________ авыл җирлеге башкарма комитеты

Урнашкан урыны:
Банк реквизитлары:
БИК һәм Россия Банкы учреждениесенең исеме
Исәп-хисап счеты
Шәхси счет
ИНН/КПП
ОГРН
ОКТМО

## IX. Якларның имзалары

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

___________/__________________
(имза) (ФИА)

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы ________________ авыл җирлеге башкарма комитеты

___________/___________________
(имза) (ФИО)

Кушымта
2021 елның ________ № ___
Килешүгә

Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Биектау муниципаль районы бюджетыннан бирелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап

| Учреждение исеме | Бирелгән субсидия күләме, ш.ис. (сум): | | Нинди максатларга | Файдаланган субсидия күләме, ш.ис. (сум): | | Түләү йөкләмәсе номеры һәм дата | Үзләштерелмәгән акча күләме (сум) | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ТР бюджетыннан | Район бюджетыннан | | ТР бюджетыннан | Район бюджетыннан | | ТР бюджетыннан | Район бюджетыннан |
| | | | | | | | | |